ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АНАТЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422643, с.Анатыш,
ул. Клубная, дом 17

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АНАТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422643, Анатыш,
Клуб урамы, 17 нче йорт,

Тел.: (84361) 23285, факс: (84361) 23285, e-mail:Anat.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Анатыш авылы №16 2024 елның 7 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25.09.2024 ел, №15 карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Анатыш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25.09.2024 ел, №15 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:: 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: "Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның законсыз тутырылган электрон рәвешендәге кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге информацион хәбәр ярдәмендә бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2.Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Анатыш авылы, Клуб урамы, 17 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шиланка авылы, Яр Чаллы ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында

һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге башлыгы К.К.Җамалиев